СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

23.03.2020 с. Верхний Услон № 56-639

Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарәләрне оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.2003 елның 131-ФЗ номерлы Федераль кануныннa, “Россия Федерациясе субъектлары дәүләт властеның закон чыгаручы (сайлап куелган) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында” 06.10.1999 елның 184-ФЗ номерлы Федераль законына, ”Татарстан Республикасында җирле үзидарәләр турында” Татарстан Республикасы кануныннa, Югары Ослан муниципаль районы Уставына таянып,

Югары Ослан муниципаль районы советы
Карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Советының 2018 елның 25 апрелендәге 33-361 номерлы карары белән расланган Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты статусы турында Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 9 статьясындагы 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район Советы депутаты хокуксыз:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының гомуми җыелышында (конференция) Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) Россия Федерациясе субъекты

законында билгеләнгән тәртиптә алдан белдерү кәгазе белән түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күзаллау;

г) идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә күзаллау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә;

5) граждан, административ яки җинаять эше яки административ хокук бозу эше буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) буларак катнашырга;

6) федераль законнарда башкасы каралмаган булса, дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында өченче затлар эшләре буенча ышанычлы яисә бүтән вәкил булырга;

7) Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачарга һәм аларга ия булырга, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга;

8) хезмәттән тыш максатларда бары тик хезмәт эшчәнлеге өчен генә билгеләнгән мәгълүматны, матди-техник, финанс һәм мәгълүмати тәэминат чараларын кулланырга;

9) район Башлыгы вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән зат буларак публикацияләр һәм чыгыш ясаган өчен гонорар алырга;

10) Россия Федерациясе законнарында каралмаган хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (ссудалар, акчалата һәм башка бүләкләүләр, хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү) һәм физик һәм юридик затлардан бүләкләр алырга. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган бүләкләр муниципаль район милке дип таныла һәм акт буенча тиешле муниципаль органга тапшырыла. Район Башлыгы вазыйфасын, даими нигездә эшләүче муниципаль вазыйфаны биләгән, беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына һәм башка рәсми чарага бәйле рәвештә алынган бүләкне тапшырган зат аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

11) билгеләнгән тәртипкә карамастан, чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм бүтән мактау билгеләрен (фән һәм спорт өлкәләреннән тыш) кабул итәргә;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган хезмәт командировкаларыннан тыш, физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән, муниципаль органнарның чит дәүләтләрнең дәүләт яки муниципаль органнары, халыкара яки чит ил оешмалары белән килешүләре буенча, Россия Федерациясеннән читкә чыгарга;

13) хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле булмаган максатларда, Федераль закон нигезендә хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә аңа билгеле булган керү чикләнгән мәгълүматка кертелгән мәгълүматларны таратырга яки кулланырга».

2. Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты статусы турындагы Нигезләмә текстын яңа редакциядә расларга (1 кушымта).

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокук мәгълумат рәсми порталында һәм Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Югары Ослан муниципаль районы Советының хокук, тәртип саклау һәм регламент буенча даими комиссиясенә тапшырырга.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М.Г. Зиатдинов

Югары Ослан муниципаль районы
Советының 23март, 2020 ел,
56-639 номерлы карарына
1 кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты статусы турында
Нигезләмә

Әлеге Нигезләмә Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты (алга таба - депутат) хокукларын һәм бурычларын билгели, үз вәкаләтләрен гамәлгә ашырганда төп хокукый һәм социаль гарантияләрне күздә тота.

1 бүлек. Гомуми Нигезләмәләр.

Статья 1. Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты

Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты булып Татарстан Республикасы Сайлау кодексы белән туры китереп, гамәлдәге канун, Югары Ослан муниципаль районы Уставы һәм бу Кагыйдәнамәдә каралган Югары Ослан муниципаль районы Советында закон чыгару һәм башка вәкаләтләрне тормышка ашырырга вәкил итеп сайланган халык вәкиле тора.

Статья 2. Депутатның вәкаләтлек вакыты

Депутатның вәкаләтлек вакыты аны Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты итеп сайлаган көннән башлана һәм бу Кагыйдәнамәнең 3 маддәсендә каралган очраклардан кала, яңа чакырылыш Югары Ослан муниципаль районы Советы эшли башлаган көннән туктатыла.

Статья 3. Депутатның вәкаләтлек вакыты алдан туктатылу

1. Депутатның вәкаләтләре вакытыннан алда түбәндәге очракларда туктатыла:
1) үлгән очракта;
2) үз теләге буенча отставкага киткәндә;
3) суд тарафыннан хезмәткә яраксыз яки чикле эшкә яраклы дип табылса;
4) суд тарафыннан билгесез юкка чыккан дип яки үлгән дип табылса;
5) аңа карата гаепләү суд карары законлы көченә керсә;
6) Россия Федерациясе чикләренә яшәргә китсә;
7) Россия Федерациясе гражданлыгы бетсә, Россия Федерациясе халыкара килешү катнашучысы - чит дәүләт гражданлыгы бетә, шуңа күрә чит ил гражданины Районның җирле үзидарә органнарына сайлана ала, чит дәүләт гражданлыгын яки торырга рөхсәт алса;
8) сайлаучылар тарафыннан чакыртылып алынса;
9) Район Советы вәкаләтләре вакытыннан алда туктатылса;
10) хәрби хезмәткә алынса яки аны алыштыра торган альтернатив граждан хезмәтенә алынса;
11) “Коррупциягә каршы тору турында” 25 декабрь, 2008 ел, 273-ФЗ номерлы Федераль канунында, “Россия территориясеннән читтә булган чит ил банкларында акча саклау һәм счётлар (вкладлар) ачу аерым категория затларга тыелуы турында” 7 май, 2013 ел, 79-ФЗ номерлы Федераль канунында, “Дәүләт вазифасын башкаручы шәхесләрнең һәм башка шәхесләрнең чыгымнары белән керемнәре туры килүне

контрольдә тоту турында” 3 декабрь, 2012 ел, 230-ФЗ номерлы Федераль кануннарында билгеләнгән чикләүләр һәм тыюларны сакламаса һәм вазифаларын үтәмәсә;

12) гамәлдәге канунда билгеләнгән башка очракларда.

2. Район Советы депутаты вәкаләтләре туктатылган көн күрсәтелгән әлеге маддәнең 1 пунктының 1-7, 10, 11 ярдәмче пунктларында күрсәтелгән очракларда Район Советы тарафыннан Район Советы депутатының вәкаләтләрен туктату турындагы карар кабул ителә. Әлеге карар депутат вәкаләтләре туктатылган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә, әгәр бу очрак район Советы сессияләре арасында булса, өч айдан да соңга калмыйча кабул ителә.

Әлеге маддәнең 1пунктының 8 кече пунктында каралган очракларда Район Советы депутаты бәяләмәсе буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен рәсми рәвештә бастырып чыгарганнан соң Район Советы депутаты вәкаләтләре туктатыла.

Әлеге маддәнең 1 пунктының 9 ярдәмче пунктында каралган очракларда Район Советы вәкаләтләре туктатылган көннән Район Советы депутаты вәкаләтләре туктатыла.

Татарстан Республикасы Президенты Район Советы депутаты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында гариза белән мөрәҗәгать иткән очракта вәкаләтләрне вакытыннан алда туктату өчен нигез булып Район Советына әлеге гариза кергән көн тора.

Статья 4. Депутатның таныклыгы һәм күкрәккә тага торган билгесе

1. Депутатның аның шәхесен һәм Югары Ослан муниципаль районы Советы депутаты вәкаләтләрен раслаучы төп документы булган таныклыгы һәм күкрәккә тага торган билгесе бар. Бу таныклык һәм күкрәккә тага торган билгесе белән ул үзенең вәкаләтләре вакытында файдалана.

2. Депутатның таныклыгы Татарстан Республикасы дәүләт власте органнарына, җирле үзидарә органнарына тоткарлыксыз йөрү, депутат вәкаләтләрен тормышка ашыру максатыннан аларның коллегиаль органнары утырышларында катнашу хокукын бирә торган документ булып тора.

Статья 5. Депутатның үз вәкаләтләрен тормышка ашыру шартлары

1. Депутат депутат эшчәнлеген азат ителмәгән нигездә, Югары Ослан муниципаль районы Уставы белән билгеләнгән очраклардан кала, депутат эшчәнлеген төп эш урыны буенча хезмәт һәм эш вазифаларын башкару белән берләштереп тормышка ашыра.

Статья 6. Депутатның эшчәнлек формалары

1. Депутатның эшчәнлек формалары булып түбәндәгеләр тора:

а) район Советы утырышларында катнашу;

б) район Советы тарафыннан оешкан комиссияләр эшендә катнашу;

в) парламент тыңлауларында катнашу;

г) район Советы карарлары проектларын кертү;

д) депутат сорауларын кертү;

е) дәүләт власте органнарына, җирле үзидарә органнарына, җәмәгать оешмаларына һәм аларның дәүләт хезмәтендәге затларына тәкъдимнәрен кертү;

ж) депутат мөрәҗәгатен җибәрү;

з) гражданнарның хокукларын бозу очракларын кичекмәстән туктату буенча чара күрү таләбе белән тиешле дәүләт хезмәтендәге шәхесләргә мөрәҗәгать итү;
и) сайлаучылар белән эшләү;
к) район Советы депутатлар оешмалары эшендә катнашу.
2. Депутат эшчәнлеге шулай ук федераль кануннар, Татарстан Республикасы кануннары, Югары Ослан муниципаль районы Уставы, Югары Ослан муниципаль районы Советы Нигезләмәсе белән каралган башка формаларда тормышка ашырыла.

Статья 7. Депутатның сайлаучылар белән үзара мөнәсәбәтләре

1. Депутат сайлау округы сайлаучылары белән, шулай ук дәүләт органнары һәм җирле үзидарә органнары белән, үзенең сайлау округы территориясендә урнашкан предприятие коллективлары, оешмалар белән элемтәдә тора.
2. Депутат сайлаучыларның мөрәҗәгатьләрен карый, гражданнарны кабул итүне алып бара, тиешле дәүләт власте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм җәмәгать оешмаларына тәкъдимнәрен кертә, шулай ук айга бер тапкыр сайлаучыларны кабул итүне үткәрә.
3. Депутат үзенең эшчәнлеге турында сайлаучыларга алар белән очрашу вакытында, шулай ук массакүләм мәгълумат чаралары аша хәбәр итеп тора.
Депутатның сайлаучылар белән очрашулары бинада, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук аларны үткәрү тормышны тәэмин итү объектларының, транспорт һәм иҗтимагый инфраструктура, элемтә эшчәнлеген бозуга китермәгән, җәяүлеләр һәм транспорт йөрешенә, яки гражданнарның торак йортларга, транспорт һәм иҗтимагый инфраструктура объектларына керү юлларында комачаулык тудырмаган шартларда, ишегаллары эчендәге территорияләрдә үткәрелә. Мондый очрашулар турында тиешле муниципаль берәмлекнең җирле үзидарә органнарына белдерү таләп ителми. Шул ук вакытта депутат күрсәтелгән органнарга алдан ук аларны үткәрү вакыты һәм урыны турында хәбәр итергә хокуклы.
Җирле үзидарә органнары сайлаучылар белән очрашу үткәрү өчен махсус бүлеп бирелгән урыннарны билгелиләр, шулай ук җирле үзидарә органнары тарафыннан сайлаучылар белән очрашу өчен бирелгән биналарның исемлеген һәм аларның бирелү тәртибен билгелиләр.
Депутатның сайлаучылар белән очрашулары җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, йөрешләр һәм пикетлар турында Россия Федерациясе кануны белән туры китереп халык алдындагы чара формасында үткәрелә.

Статья 8. Депутат тарафыннан депутат этикасы кагыйдәләрен саклау

1. Район Советы депутаты район Советы тарафыннан расланган, шул исәптән түбәндәге депутат йөкләмәләрен үз эченә алган депутат этикасы Кагыйдәләрен үтәргә тиеш:
1) җирле үзидарә органнары эшендә катнашудан тыелып торырга һәм җирле үзидарә органнары эшчәнлегенә, оешмаларга, вазифаи затларга, муниципаль хезмәткәрләргә һәм гражданнарга, аларның туганнарына яки үзләренә кагылышлы мәсъәләләрне чишкәндә, депутат статусын кулланып, йогынты ясарга тиеш түгел;
2) депутат вазифаларын объектив башкаруда шикләнүләр туганда эш – гамәлләреннән тыелып торырга тиеш, шулай ук Район Советы дәрәҗәсенә яки абруена зыян китерергә сәләтле булган конфликт ситуацияләрне булдырмый калырга тиеш;

3) мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрү бурычын күздә тоткан затның шәхси кызыксынуы (турыдан - туры яки туры туры кагылмаган) вазыйфаи (хезмәт) бурычларының тиешле, объектив һәм гадел үтәлүенә (вәкаләтләрне гамәлгә ашыру) йогынты ясый яисә йогынты ясый ала торган мәнфәгатьләр каршылыгы барлыкка килү куркынычы янаганда;

4) Район Советы урнаштырган халык алдында чыгыш ясау кагыйдәләрен үтәргә тиеш;

5) федераль кануннарга туры китереп, конфиденциаль характердагы мәгълуматларга караган мәгълуматларны, Район Советы депутаты вазифаларын башкарган вакытта депутат эшчәнлеге белән бәйле булмаган үзенә билгеле булган мәгълуматны таратырга һәм шул максатларда кулланырга тиеш түгел;

6) депутат вазифаларын башкару аркасында физик һәм юридик затлардан бүләкләр (бүләкләр, акчалата бүләкләр, ссудалар, булышлык, күңел ачулар, яллары, транспорт чыгымнары өчен түләүләр һәм башка бүләкләр) алмаска тиеш.

Статья 9. Депутат эшчәнлеге белән бәйле булган чикләүләр

1. Район Советы депутаты үзенең вәкаләтләре вакытында Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Дәүләт Думасы депутаты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесенең Федерация Советы әгъзасы, Татарстан Республикасы дәүләт власте закон чыгаручы (сайлап куелган) органнары депутаты була алмый, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының башка вазифаларын алып тора алмый, шулай ук дәүләт граждан хезмәте вазифаларын һәм муниципаль хезмәт вазифаларын башкара алмый. Федераль канун белән башка нәрсә каралмаган булса, район Советы депутаты бер үк вакытта башка муниципаль берәмлек Советының депутат вәкаләтләрен башкара алмый..

2. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы район Советы депутаты хокуксыз:

1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) түбәндәге очраклардан тыш коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә (сәяси партия, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайлау органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативларының гомуми җыелышында (конференция) Россия Федерациясе субъектының югары вазыйфаи затына (Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең югары башкарма органы җитәкчесенә) Россия Федерациясе субъекты законында билгеләнгән тәртиптә алдан белдерү кәгазе белән түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күзаллау;

г) идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә оештыруны, гамәлгә куючысы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен яки муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә күзаллау;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;

3) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылык, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яки күзәтчелек советлары, Россия Федерациясе территориясендә эшләүче чит ил коммерцияле булмаган хөкүмәтнеке булмаган һәм аларның структур бүлекчәләре составына керергә;

5) граждан, административ яки җинаять эше яки административ хокук бозу эше буенча яклаучы яисә вәкил (законлы вәкиллек очракларыннан тыш) буларак катнашырга;

6) федераль законнарда башкасы каралмаган булса, дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында өченче затлар эшләре буенча ышанычлы яисә бүтән вәкил булырга;

7) Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан чит ил банкларында счетлар (кертемнәр) ачарга һәм аларга ия булырга, кулдагы акча һәм кыйммәтләрне сакларга, чит ил финанс инструментларына ия булырга һәм (яки) алардан файдаланырга;

8) хезмәттән тыш максатларда бары тик хезмәт эшчәнлеге өчен генә билгеләнгән мәгълүматны, матди-техник, финанс һәм мәгълүмати тәэминат чараларын кулланырга;

9) район Башлыгы вазыйфасын, муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән зат буларак публикацияләр һәм чыгыш ясаган өчен гонорар алырга;

10) Россия Федерациясе законнарында каралмаган хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләкләүләр (ссудалар, акчалата һәм башка бүләкләүләр, хезмәтләр, күңел ачу, ял итү, транспорт чыгымнары өчен түләү) һәм физик һәм юридик затлардан бүләкләр алырга. Беркетмә чараларына, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган бүләкләр муниципаль район милке дип таныла һәм акт буенча тиешле муниципаль органга тапшырыла. Район Башлыгы вазыйфасын, даими нигездә эшләүче муниципаль вазыйфаны биләгән, беркетмә чарасына, хезмәт командировкасына һәм башка рәсми чарага бәйле рәвештә алынган бүләкне тапшырган зат аны Россия Федерациясе норматив хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә сатып алырга мөмкин;

11) билгеләнгән тәртипкә карамастан, чит дәүләтләрнең, халыкара оешмаларның, сәяси партияләрнең, бүтән иҗтимагый берләшмәләрнең һәм башка оешмаларның мактаулы һәм махсус исемнәрен, бүләкләрен һәм бүтән мактау билгеләрен (фән һәм спорт өлкәләреннән тыш) кабул итәргә;

12) Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла торган хезмәт командировкаларыннан тыш, физик һәм юридик затлар акчалары исәбеннән,

муниципаль органнарның чит дәүләтләрнең дәүләт яки муниципаль органнары, халыкара яки чит ил оешмалары белән килешүләре буенча, Россия Федерациясеннән читкә чыгарга;

13) хезмәт вазыйфаларын үтәүгә бәйле булмаган максатларда, Федераль закон нигезендә хезмәт вазыйфаларын үтәү белән бәйле рәвештә аңа билгеле булган керү чикләнгән мәгълүматка кертелгән мәгълүматларны таратырга яки кулланырга.

3 Район Советы депутаты Россия Федерациясенең норматив-хокукый актларында билгеләнгән тәртиптә, вазыйфаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яки китерә ала торган шәхси кызыксынучанлык барлыкка килү турында хәбәр итәргә, шулай ук мондый конфликтны булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрергә бурычлы.

Статья 10. Депутатның, аның хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълумат

1. Район Советы депутаты ел саен, отчёт чорыннан соң елның 30нчы апреленнән дә соңга калмыйча тапшырырга тиеш:

1) отчёт чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) бөтен чыганаклардан алынган үзенең керемнәре турында мәгълуматны (акчалата бүләкләрне, пенсияне, акчалата ярдәмне, башка түләүләрне кертеп), шулай ук милек хокукында аныкы булган мөлкәте турында, отчёт чоры ахырына үзенең мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълуматны;

2) отчёт чоры өчен (1 гыйнвардан 31 декабрьгә кадәр) бөтен чыганаклардан алынган хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының керемнәре турында мәгълуматны (акчалата бүләкләрне, пенсияне, акчалата ярдәмне, башка түләүләрне кертеп), шулай ук милек хокукында аларныкы булган мөлкәте турында, отчёт чоры ахырына аларның мөлкәт характерындагы бурычлары турында мәгълуматны;

3) отчёт чоры өчен үзенең, хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында, шулай ук җир кишәрлеге сатып алу, башка күчемсез милек, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав капиталы пайларында катнашу ) сатып алу буенча алар тарафыннан календарь елында (отчёт чоры) аның тарафыннан, хатыны (ире) яки (һәм) балигъ булмаган балалары тарафыннан башкарылган һәрбер килешү буенча мәгълуматны, әгәр бу килешүләрнең гомуми суммасы соңгы өч ел эчендә әлеге шәхеснең һәм аның хатынының (иренең) төп кеременнән артып китсә, бу килешүләр акча алган чыганаклар хисабына башкарылуы турында мәгълуматны тапшырырга тиеш.

4. Депутат Татарстан Республикасы Президентына керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат бирә.

5. Депутат керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында үзләре тапшырган белешмәләрдә нинди дә булса мәгълүматлар чагылдырылмавын яки тулысынча күрсәтелмәвен ачыклаган очракта, алар Татарстан Республикасы Президентына керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшырырга хокуклы

Депутат әлеге Нигезләмәнең 1 пунктында күрсәтелгән срок тәмамланганнан соң бер ай эчендә төгәлләштерелгән белешмәләрне тапшыра ала.

6. Керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълүмат тапшырмау яки объектив сәбәпләр аркасында керемнәре, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында мәгълуматны район

Советы депутаты тарафыннан Татарстан Республикасы Президенты билгеләгән тәртиптә карап тикшерелергә тиеш.

7. Керемнәре, чыгымнары, милке һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшырмаган, шулай ук белә торып дөрес булмаган яки тулы булмаган белешмәләр биргән өчен район Советы депутаты Россия Федерациясе законнары нигезендә җавап тота.

8. Район Советы депутаты тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, милек һәм милек характерындагы йөкләмәләр турындагы белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү Татарстан Республикасы Президенты карары буенча Татарстан Республикасы законы белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Статья 11. Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтының “Интернет ”мәгълумати - телекоммуникацион челтәрендә депутатлар тарафыннан керемнәре, чыгымнары, мөлкәте, мөлкәт характерындагы бурычлары турында тапшырган мәгълуматларны, акчаны алу чыганаклары турында, һәм бу мәгълуматларны массакүләм мәгълумат чараларында бастырып чыгару өчен аларның сораулары буенча бирү

1. Югары Ослан муниципаль районы рәсми сайтының “Интернет” мәгълумати - телекоммуникацион челтәрендә (алда- рәсми сайт) керемнәр, чыгымнар, мөлкәт, мөлкәт характерындагы бурычлар турында аларның сораулары аркасында түбәндәге мәгълуматлар урнаштырыла һәм бастырып чыгару өчен массакүләм мәгълумат чараларына тапшырыла:

1) депутатның, аның хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының милкендә булган күчемсез милек объектларының һәрберсенең төрен, мәйданын һәм урнашкан илен күрсәткән исемлеге;

2) депутатның, аның хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының милке булган төрен, маркасын күрсәтеп транспорт чаралары исемлеге;

3) депутатның, аның хатынының (иренең), балигъ булмаган балаларының декларация ясалган еллык кереме;

4) чыгымнары турында мәгълумат.

2. Кагыйдәнамәнең әлеге маддәсенең 1 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт, мөлкәт характерындагы бурычлар турында мәгълуматлар депутат тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт, мөлкәт характерындагы бурычлар турында белешмә бирү өчен билгеләнгән вакыт үткәннән соң 14 көн эчендә рәсми сайтта бастырылып чыгарыла.

3. Кагыйдәнамәнең әлеге маддәсенең 1 пунктында күрсәтелгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт, мөлкәт характерындагы бурычлар турында мәгълуматларны рәсми сайтта урнаштыру Югары Ослан муниципаль районы Советы аппараты тарафыннан тормышка ашырыла.

## II бүлек. Депутат эшчәнлегенең гарантияләре

Статья 12. Депутатның закон чыгару инициативасына хокукы

1. Район Советы депутаты район Советына проектлар карарларын кертү формасында тормышка ашырыла торган закон чыгару хокукы инициативасына ия.

2. Район Советына проектлар карарларын кертү тәртибе район Советы Регламенты белән билгеләнә.

Статья 13. Депутатның район Советы эшчәнлегендә, район Советының даими комиссиялләре эшчәнлегендә катнашуы

1. Район Советы депутаты район Советы, шулай ук аның әгъзасы булган район Советының даими комиссиясе карап тикшергән барлык мәсьәләләр буенча мөһим тавыш бирү хокукына ия.
2. Район Советы депутаты район Советы утырышларында, район Советының даими комиссияләре утырышларында Татарстан Республикасы Конституциясе, федераль һәм республика кануннары, район Уставы, район Советы Регламенты һәм әлеге Кагыйдәнамә белән туры китереп аңа бирелгән хокукларны тормышка ашыра.
3. Район Советы депутаты район Советы Регламенты билгеләгән тәртиптә аның әгъзасы булган район Советы утырышларында, район Советының даими комиссияләре утырышларында үзе катнаша. Күрсәтелгән утырышларда кичерерлек сәбәпләр аркасында катнаша алмауы турында район Советы депутаты алдан ук район Советы рәисенә, аның әгъзасы булган район Советы даими комиссиясе рәисенә хәбәр итә.
4. Район Советы депутаты район Советының даими комиссияләренең теләсә кайсы утырышында киңәш хокукы белән катнашырга хокуклы.

Статья 14. Депутатның рәсми сорауы

1. Район Советы депутаты район Советы утырышларында аларның компетенцияләренә кергән мәсьәләләр буенча район Башлыгына, җирле үзидарә органнары җитәкчеләренә, башка органнарның җитәкчеләренә рәсми сорау белән мөрәҗәгать итергә хаклы.
2. Депутатның рәсми сорауы язмача формада кертелә һәм район Советы Регламенты билгеләгән тәртиптә район Советы утырышында укып чыгыла.
3. Депутатның рәсми сорауы юнәлтелгән орган яки дәүләт хезмәтендәге шәхес аны алган көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча язмача формада аңа җавап бирергә тиеш. Җавап депутатның рәсми сорауы юнәлтелгән орган җитәкчесе яки дәүләт хезмәтендәге шәхес, яки вакытлача аның вазифасын башкаручы шәхес тарафыннан имзаланырга тиеш.

Статья 15. Депутатның тәкъдимнәре

1. Район Советы депутаты тарафыннан район Советы утырышларында язмача рәвештә кертелгән тәкъдимнәре район Советы тарафыннан карала яки карап тикшерү өчен дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләргә җибәрелә.
2. Әлеге Кагыйдәнамәнең 1 пунктында күрсәтелгән район Советы депутаты тәкъдимнәре юнәлтелгән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр аларны бер айдан да соңга калмыйча карап чыгырга һәм нәтиҗәләре турында район Советына һәм депутатка хәбәр итергә тиеш. Тәкъдимне кабул итмәгән очракта төпле җавап бирелә.

Статья 16. Депутат мөрәҗәгате

1. Депутат мөрәҗәгате булып депутатның язмача формада күрсәтелгән органнар һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр компетенциясендә булган мәсьәләләр буенча дәүләт власте органнарына, җирле үзидарә органнарына, организацияләр һәм иҗтимагый оешмаларга, шулай ук дәүләт хезмәтендәге шәхесләргә аның депутат эшчәнлеге белән бәйле булган хәбәрләрне һәм мәгълуматларны алу максатыннан мөрәҗәгате санала.

2. Депутат мөрәҗәгате депутат бланкында рәсмиләштерелә һәм депутат тарафыннан мөстәкыйль рәвештә җибәрелә.

3. Органнар һәм дәүләт хезмәтендәге шәхесләр компетенциясендә булган мәсьәләләр буенча дәүләт власте органнарына, җирле үзидарә органнарына, организацияләр һәм иҗтимагый оешмаларга, шулай ук дәүләт хезмәтендәге шәхесләргә килгән депутат мөрәҗәгате, мөрәҗәгатьне теркәгән көннән соң җиде көн эчендә карап чыгыла, һәм күрсәтелгән сроктан соңга калмыйча соралган мәгълумат яки хәбәр район Советы депутатына тапшырыла. Өстәвенә, дәүләт яки коммерция серен тәшкил иткән мәгълуматлар федераль канун билгеләгән тәртиптә тапшырыла.

4. Сирәк була торган очракларда, өстәмә тикшерү үткәрү яки депутат мөрәҗәгате буенча өстәмә материаллар соратып алу кирәк булганда, мөрәҗәгатьне карау вакыты аны теркәгән көннән соң 30 көнгә кадәр озынайтыла. Бу Кагыйдәнамәнең әлеге маддәсенең 3 пунктында күрсәтелгән дәүләт хезмәтендәге шәхесләр район Советы депутатына аның мөрәҗәгатен карап чыгу вакыты озынайтылганы турында язмача рәвештә хәбәр итергә тиеш.

5. Район Советы депутаты мөрәҗәгатендә куелган сорауларны карап чыгуда турыдан – туры катнашырга хокуклы. Карап чыгу вакыты турында депутатка өч көннән дә соңга калмыйча хәбәр итергә тиешләр.

6. Депутат мөрәҗәгатенә җавап мөрәҗәгать тапшырылган дәүләт хезмәтендәге шәхес яки вәкаләтле зат тарафыннан имзаланырга тиеш.

Статья 17. Район Советы депутатының дәүләт хезмәтендәге шәхесләр тарафыннан кабул итүгә хокукы

1. Район Советы депутаты депутат эшчәнлеге мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары җитәкчеләре һәм башка дәүләт хезмәтендәге шәхесләр тарафыннан чиратсыз кабул итү хокукы белән файдалана ала.

2. Район Советы депутаты дәүләт хезмәтендәге шәхескә турыдан-туры, яки дәүләт хезмәтендәге шәхеснең кабул итү бүлмәсе (секритариат) аша телдән яки язмача мөрәҗәгать итергә хаклы.

3. Телдән мөрәҗәгать иткән очракта кабул итү вакыты дәүләт хезмәтендәге шәхес тарафыннан район Советы депутаты белән килешеп билгеләнә, ә район Советы депутаты язмача мөрәҗәгать иткән очракта кабул итү вакыты дәүләт хезмәтендәге шәхес тарафыннан депутат мөрәҗәгатен алган вакыттан өч көннән дә соңга калмыйча билгеләнә.

4. Район Советы депутатын кабул итү мөмкин булмаган очракта дәүләт хезмәтендәге шәхес өч көн эчендә депутат белән килешеп башка кабул итү вакытын билгели.

Статья 18. Депутатның мәгълуматны алуга һәм таратуга хокукы

1. Район Советы аппаратының дәүләт хезмәтендәге кешеләре район Советы Регламенты белән билгеләнгән тәртиптә район Советы депутатын район Советына килгән документлар белән тәэмин итәләр.
2. Район Советы депутаты федераль кануннар белән каралган тәртиптә үзенең эшчәнлеге мәсьәләләре буенча массакүләм мәгълумат чараларында чыгыш ясарга хокуклы.

Статья 19. Район Советы депутатының хезмәт хокуклары гарантияләре

1. Даими нигездә эшләүче район Советы депутатының вәкаләтлек вакыты гамәлдәге канун белән туры китереп гомуми һәм өзлексез хезмәт стажына, белгечлеге буенча хезмәт стажына керә.
2. Район Советы депутаты эшчәнлегенең башка гарантияләре район Уставы белән билгеләнгән.

Статья 20. Депутат эшчәнлеген башкарганда тоткарлыклар булдырган өчен җаваплылык

Әлеге Кагыйдәнамәнең кагыйдәләрен җирле үзидарә органнары, организацияләр һәм иҗтимагый оешмаларның дәүләт хезмәтендәге шәхесләре тарафыннан үтәмәүе, шул исәптән депутат сораулары буенча мәгълуматны һәм җавапларны бирү вакытын һәм тәртибен үтәмәгән өчен, ялган мәгълумат биргән өчен, мәгълумат бирүдә нигезсез баш тарткан өчен, аны тапшырудан читләшкән өчен, депутатларны кабул итү кагыйдәләрен бозган өчен канун белән каралган җаваплылыкка тартыла.

Совет рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы М.Г.Зиатдинов